СОВЕТ
КУШМАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КОШМАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.02.2021 ел Кошман ав. № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә керми торган һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Әйләнә – тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә керми торган һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлещен контрольгә алуны үз өстемә алам.

Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Сафина

Совет Кушманского сельского поселения
Кошман авыл җирлеге Советы
ИНН 1621001104

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Советының
2021 елның 15 февралендәге
2 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегете рриториясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә керми торган һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында

НИГЕЗЛӘМӘ

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә керми торган һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибен билгели.

1. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

яшел утыртмалар - табигый һәм ясалма килеп чыккан агач, куаклыклар һәм үләнчел үсемлекләре (паркларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәклекләрне, шулай ук аерым торучы агачларны һәм куакларны да кертеп);

табигать территорияләре - бердәм географик (климат) шартларында формалашкан җирлек, туфрак, үсемлекләр рельефының билгеле бер типларын берләштерүче, хуҗалык эшчәнлеге кагылмаган яисә аз кагылган территорияләр;

яшелләндерелгән җирләр - ясалма төзелгән яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), алар чикләрендә өслекнең кимендә 50 процентын үсемлекләр капламы биләгән төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең аз төзелгән участоклары;

урманландырылган территорияләр - табигый килеп чыккан урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигать территорияләре участоклары;

агач – үсентеләрдән кала, кәүсә диаметры 5 см дан, биеклеге 1,3 м дан ким булмаган ачык беленеп торган кәүсәле үсемлек;

куаклык - туфрак өслегендә тармакланган күпьеллык күптармаклы (агачтан аермалы буларак) үсемлек;

үләнкапламы - газон, табигый үлән капламы;

әрәмәлекләр – нинди дә булса урында тыгыз үсүче үсемлекләр, куаклар;

яшел массив – бердәм чатыр ясаучы өлкән (15 яшьтән өлкәнрәк) агачларның кимендә 50 нөсхәсе үсә торган территория участогы;

яшел утыртмаларның зарарлануы – яшел утыртмаларга аларның үсешен туктатуга китерми торган зыян китерү, шул исәптән ботакларның, тамыр системасының механик зарарлануы, кайрының бөтенлеген, тере туфрак катламының бөтенлеген бозу, яшел үсентеләрнең яисә тамыр зонасында туфракның зарарлы матдәләр белән пычрануы, ут төртү яисә башка йогынты ясау;

яшел утыртмаларны юкка чыгару (юк итү) – яшел утыртмаларны кисү яисә аларның үсешен туктатуга китергән башка төрле зарарлану;

компенсация яшелләндерүе - 2 коэффициенты белән юкка чыгарылган яки зарарланганнар урынына алмашка яшел утыртмалар җитештерү.

## 2. Яшел утыртмаларны саклауның төп принциплары

Авыл җирлеге территориясендә үсә торган яшел утыртмалар саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкара һәм сакланырга тиеш.

2.1.Авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел утыртмалар (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш.

2.2.Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрнең сакланышы һәм аларны үстерү өчен шартлар тудыру бурычлары:

2.2.1.оешмаларга үзләре белдергән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә - әлеге оешмалар җитәкчеләренә;

2.2.2.милектәге яки арендадагы участокларда – юридик затларга һәм гражданнарга - милекчеләр яки арендаторларга йөкләнә.

2.3.Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, алардан файдаланучылар һәм арендаторлары яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәргә, яшел утыртмаларны тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.

2.4.Әлеге Нигезләмә авыл җирлеге территориясендә милек рәвешләренә бәйсез рәвештә агач – куак үсентеләрен кисүгә бәйле проектлау, төзелеш, ремонтлау һәм башка эшләрне алып баручы барлык гражданнарга һәм оешмаларга кагыла.

2.5.Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2.6.Җир кишәрлеген сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документациясендә яшел утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысын тулысынча бәяләү турында мәгълүмат булырга тиеш.

2.7.Яшел утыртмаларның тереклек эшчәнлеген тәэмин итү белән тәңгәл килми торган яшелләндерү территорияләрен һәм яшел массивларны куллану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

3.1.Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне рөхсәтсез кисү тыела.

3.2.Авыл җирлеге территориясендә агачларны һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла.

3.3.Рөхсәт бирү мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурычы булмаган очракта гамәлгә ашырыла.

3.4.Яшел утыртмаларны кисү эшләре билгеләнгән нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә гариза бирүче акчалары исәбеннән башкарыла. Агач бары тик аттестацияләнгән белгечләр тарафыннан гына кисү рөхсәт ителә.

3.5.Киселгән яшел утыртмаларны һәм кисү калдыкларын төяү һәм алып китү эше башлап җибәргәннән соң өч көн эчендә мөрәҗәгать итүче хисабына

башкарыла. Эш урынында киселгән яшел утыртмаларны һәм киселгән калдыкларны саклау тыела.

3.6.Территориянең кисү турына якын урнашкан территориядә газон, яшел үсентеләр зарарланган очракта, эшләр җитештерүче аларны территориянең хуҗасы һәм контроль органнары белән алар компетенциясе чикләрендә килештереп, зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, аларны мәҗбүри рәвештә торгызу эшләрен башкара.

3.7.Агач кискән өчен түләмичә агач һәм куакларны кисү авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

тәрбияләү, санитар кисүләр һәм яшел үсентеләрне реконструкцияләү;

авария хәлендәге һәм башка гадәттән тыш хлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау;

Дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм иҗтимагый биналарда яктылыкны боза торган агач һәм куакларны кисү;

авария хәлендәге (төшү куркынычы тудыручы, корыган) агачларны һәм куакларны кисү.

Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләрне кисүне гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчегә авыл җирлеге Башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсацион яшелләндерү үткәрергә кирәк.

3.8.Авария хәлендәге, корыган һәм куркынычсызлыкка куркыныч тудыручы яшел утыртмалар комиссия тикшерүе нигезендә киселә.

3.9.Яшел утыртмаларны санкцияләнмәгән кисүя исә юкка чыгару дипт үбәндәге очраклар танылa:

агачларны һәм куакларны рөхсәтсез яки рөхсәт белән рөхсәттә күрсәтелмәгән урында, күләмдә һәм башка агач токымнарын кисү;

яндыру яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агачларны һәм куакларны юк итү яки зарарлау;

кәүсәне боҗралау яки төпләү;

үсә торган агачларны һәм куакларны үсешләре туктатылганчыга кадәр зарарлау;

агач һәм куакларның агынты сулар, химик матдәләр, калдыклар һәм башкалар белән зарарлануы;

корыган агачларны рөхсәтсез кисү;

үсә торган агачларның һәм куакларның башка зарарланулары.

## 4. Компенсацион яшелләндерү

4.1.Компенсацион яшелләндерү рөхсәт ителгән кисүләр, яшел үсентеләрне законсыз зарарлау яки юкка чыгару очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсацион яшелләндерү якындагы сезонда, агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен яраклы, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару факты билгеләнгән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2.Компенсацион яшелләндерү аларның мәнфәгатьләрендә яисә хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару килеп чыккан гражданнар яисә юридик затлар акчалары исәбеннән башкарыла.

4.3.Әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларга китерелгән зыян натураль формада 2 коэффицент белән юкка чыгарылган яшел үсентеләрне яңадан торгызу-

компенсацион яшелләндерү рәвешендә түләнергә тиеш.

5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда яшел утыртмаларны саклау

5.1.Авыл җирлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел утыртмаларны яклау таләпләрен үтәгән килеш алып барыла.

5.2.Яшел территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир участоклары, аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган килеш һәм кулланылырга тиеш түгел.

5.3.Яшел утыртмалар утыртылган җир кишәрлекләрендә төзелеш алып барганда, проект алды документациясендә киселергә тиешле яшел утыртмаларга бәя бирелергә тиеш.Мондый очракларда зыянны каплау киселгән агач өчен алдан түләү һәм әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә компенсацион яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Эшмәкәрлек эшчәнлеге башкарганда яшел утыртмаларны саклау

6.1.Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда сәүдә һәм башка эшмәкәрлек эшчәнлеге, авыл җирлеге Башкарма комитеты рөхсәтеннән башка эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда гамәлгә ашырганда шартлау куркынычы булган, ут куркынычы булган һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел утыртмаларга зыян китерү яисә аларны юкка чыгару тыела.

7. Административ җаваплылык.

7.1.Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.